ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

# Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп өч елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Мәскәү суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Ишкинина Альбина Илсур кызын;

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча:
4 нче суд участогына – Әхмәтова Юлия Ильяс кызын;

Татарстан Республикасы Нурлат суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Смирнова Светлана Юриевнаны;

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет суд районы буенча:
5 нче суд участогына – Мөбарәкҗанова Румия Роберт кызын.

2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп вәкаләтләр чоры чикләнмәгән вакытка түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Яңа Савин суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Гомәрова Рената Илгизәр кызын;

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Иксанова Сабина Рөстәм кызын;

Татарстан Республикасы Чистай суд районы буенча:
3 нче суд участогына – Төхфәтуллин Илнур Әнвәр улын.

3. Әлеге карарның 2 пункты нигезендә сайланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының вәкаләтләре чоры алдагы вәкаләтләр чоры тәмамланган көннән башлана.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2559-VI ДС